СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 5-29 от «19» ноября 2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга (теркәлеп килә).

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына (Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенә) әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасында расланганнан соң биш көн эчендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авылы җирлеге муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны муниципаль район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

000061